| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11.12.2024 г.Казань № 359-49/кс-2024

«Восток – Энерго» җитештерү-коммерция фирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 20.11.2020 ел, №246-79/кс-2020 карары белән эчәр суга озак сроклы тарифларны 2025 елга төгәлләштерү һәм Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 20.11.2020 ел, №246-79/кс-2020 карарына үзгәрешләр кертү турында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы, «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә эшчәнлек алып баручы оешмаларның инвестиция һәм җитештерү программалары турында» 2013 елның 29 июлендәге 641 номерлы карарлары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салына торган тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15.06.2010 ел, №468 карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 11.12.2024 ел, №31-ПР беркетмәсе нигезендә, 2025 елга эчәр суга озак сроклы тарифларга һәм җайга салынулы оешманың кирәкле тулаем керемнә төзәтмәләр кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Восток – Энерго» җитештерү-коммерция фирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2021 – 2025 елларга «Восток – Энерго» җитештерү-коммерция фирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен эчәр суга тарифлар билгеләү турында» 20.11.2020 ел, №246-79/кс-2020 карары (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 15.11.2022 ел, №357-73/кс-2022, 20.10.2023

ел, №338-21/кс-2023 карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән эчәр суга озак сроклы тарифларны 2025 елга төгәлләштереп, 1 нче кушымтаны яңа редакциядә (кушымтада) бирергә.

2. Әлеге карарның 1 пункты белән төгәлләштерелгән тарифлар 2025 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2021 – 2025 елларга «Восток – Энерго» җитештерү-коммерция фирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен эчәр суга тарифлар билгеләү турында» 20.11.2020 ел, №246-79/кс-2020 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2021-2025 елларга «Восток – Энерго» җитештерү-коммерция фирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен эчәр суга тарифлар билгеләү һәм җитештерү программасын раслау турында»;

преамбулада «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салуы турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары белән» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы, «Су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыручы оешмаларның инвестиция һәм җитештерү программалары турында» 2013 елның 29 июлендәге 641 номерлы карарлары белән» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 3.1-3.2 пунктлар өстәргә:

"3.1. Әлеге карарның 3 нче кушымтасы нигезендә «Восток – Энерго» җитештерү-коммерция фирмасы» ҖЧҖ су белән тәэмин итү өлкәсендәге җитештерү программасын расларга.

3.2. Әлеге карарның 3.1 пункты белән расланган җитештерү программасы 2025 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә.»;

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә);

3 нче кушымта белән тулыландырырга (кушымта итеп бирелә).

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
20.11.2020 №246-79/кс-2020
карарына 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
11.12.2024 № 359-49/кс-2024
карары редакциясендә)

2021-2025 елларга салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы
«Восток - Энерго» ҖКФ» ҖЧҖ өчен эчәргә яраклы суга
календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Ел | Эчә торган суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|
| | Чистай муниципаль районы | | |
| 1 | «Восток - Энерго» ҖКФ» ҖЧҖ<br>(тарифлар өстәлгән хак бәясен исәпкә алмыйча күрсәтелде) | 01.01.2021 башлап<br>30.06.2021 кадәр | 22,45 |
| | | 01.07.2021 башлап<br>31.12.2021 кадәр | 23,00 |
| | | 01.01.2022 башлап<br>30.06.2022 кадәр | 23,00 |
| | | 01.07.2022 башлап<br>31.12.2022 кадәр | 23,80 |
| | | 01.01.2023 башлап<br>31.12.2023 кадәр | 24,81* |
| | | 01.01.2024 башлап<br>30.06.2024 кадәр | 24,81 |
| | | 01.07.2024 башлап<br>31.12.2024 кадәр | 28,09 |
| | | 01.01.2025 башлап | 28,09 |

| т/с | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Ел | Эчә торган суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|
| | | 30.06.2025 кадәр | |
| | | 01.07.2025 башлап 31.12.2025 кадәр | 35,61 |

* 2023 елга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 15.11.2022 №357-73/кс-2022 карары белән, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 елның 1 декабреннән 2023 елның 31 декабренә кадәр җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) индексацияләү үзенчәлекләре һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 ноябрендәге 2053 номерлы карары нигезендә төзәтмәләр кертелгән тарифлар 2022 елның 1 декабреннән гамәлгә кертелде.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
20.11.2020 №246-79/кс-2020
карарына 3 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
11.12.2024 № 358-48/кс-2024
карары редакциясендә)

**Оешманың җитештерү программасы**

**1 нче бүлек. Җитештерү программасы паспорты**

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **Җайга салынулы оешма** | «Восток - Энерго» ҖКФ» ҖЧҖ | | | |
| Урнашкан урыны | 422981, ТР, Чистай ш., Энгельс ур., 127 г/1 | | | |
| **Җайга салуның вәкаләтле органы** | Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты | | | |
| Урнашкан урыны | 420015, Казан ш., Карл Маркс ур., 66 й. | | | |
| **Җитештерү программасын гамәлгә ашыру чоры** | башлана | 01.01.2025 | тәмамлана | 31.12.2025 |

**2 нче бүлек. Су белән тәэмин итүнең һәм ташландык суларны агызуның үзәкләштерелгән системалары объектларын ремонтлау чаралары, эчә торган суның сыйфатын һәм агып төшүче суларны чистарту сыйфатын яхшыртуга юнәлдерелгән чаралар, энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру, шул исәптән транспортировкада су югалтуларын киметү чаралары исемлеге**

| **№** | **Аталышы** | **Үлчәү берәмлеге** | **Гамәлгә ашыруга финанс ихтыяҗлары** |
|---|---|---|---|
| | | | **2025** |
| 1ХВС – Эчә торган суга тариф – су белән тәэмин итү | | | |
| 1 | Агымдагы ремонт | мең сум | 96,45 |
| 2 | Капиталь ремонт | мең сум | 0,00 |
| 3 | Башка чаралар, шул исәптән эчә торган суны чистарту сыйфатын яхшыртуга, энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән чаралар | мең сум | 0,00 |

**3 нче бүлек. Су бирү күләме/Кабул ителгән су**

1ХВС – Эчә торган суга тариф – су белән тәэмин итү

| **№** | **Җитештерү эшчәнлеге күрсәткечләре** | **Үлчәү берәмлеге** | **Күрсәткеч зурлыгы** |
|---|---|---|---|
| | | | **2025** |
| 1 | Күтәрелгән су күләме | мең м3 | 51,90 |
| 2 | Технологик ихтыяҗларга су күләме | мең м3 | 0,00 |
| 3 | Читтән алынган су күләме | мең м3 | 0,69 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 4 | Чистарту корылмалары аша үткәрелгән су күләме | мең м3 | 52,58 |
| 5 | Челтәргә бирелгән су | мең м3 | 52,58 |
| 6 | Су югалту күләме | мең м3 | 1,42 |
| 7 | Су җибәрелгән, барлыгы | мең м3 | 51,16 |
| 8 | Предприятие ихтыяҗларына тотыла торган су күләме | мең м3 | 19,29 |
| 9 | Кулланучыларга су җибәрү (сату), барлыгы, шул исәптән: | мең м3 | 31,87 |
| 9.1 | су белән тәэмин итүнең башка оешмаларына | мең м3 | 0,00 |
| 9.2 | халыкка | мең м3 | 0,00 |
| 9.3 | бюджет оешмаларына | мең м3 | 0,00 |
| 9.4 | башка кулланучыларга | мең м3 | 31,87 |
| **4 нче бүлек. Җитештерү программасын гамәлгә ашыру өчен кирәкле финанс ихтыяҗлары күләме** | | | |
| **№** | **Күрсәткеч** | **Үлчәү берәмлеге** | **Күрсәткеч зурлыгы** |
| | | | **2025** |
| 1 | Җитештерү чыгымнары | мең сум | 1 203,72 |
| 1.1 | Хезмәт өчен түләү һәм төп җитештерү персоналының социаль ихтыяҗларына түләү чыгымнары | мең сум | 627,15 |
| 2 | Ремонт чыгымнары | мең сум | 186,90 |
| 3 | Административ чыгымнар | мең сум | 66,78 |
| 4 | Сату чыгымнары | мең сум | 0,00 |
| 5 | Амортизация | мең сум | 4,47 |
| 6 | Аренда һәм концессия түләүләре, лизинг түләүләре | мең сум | 0,00 |
| 7 | Салымнар һәм җыемнар | мең сум | 85,66 |
| 8 | Норматив табыш | мең сум | 0,00 |
| 8.1 | Капиталь чыгымнар | мең сум | 0,00 |
| 9 | Гарантияләүче оешманың исәпләмә эшкуарлык табышы | мең сум | 0,00 |
| 10 | Узган чорларның алынмаган керемнәре / чыгымнары | мең сум | 0,00 |
| 10.1 | Узган чорда тарифлар билгеләгәндә тарифларны җайга салу органы тарафыннан исәпкә алынмаган икътисадый нигезләнгән чыгымнар | мең сум | 201,50 |
| 10.2 | Җайга салуның узган чорларында алынмаган керемнәр | мең сум | 0,00 |
| 10.3 | Акча җитмәүне каплауга юнәлдерелгән заем акчаларына һәм үз акчаларына хезмәт күрсәтүгә бәйле чыгымнар | мең сум | 0,00 |
| 11 | Җайга салуның узган чорларының икътисадый нигезләнмәгән керемнәре / чыгымнары | мең сум | 119,40 |
| 12 | Кирәкле тулай табыш | мең сум | 1 629,63 |
| **5 нче бүлек. Җитештерү программасы чараларын гамәлгә ашыру графигы** | | | |
| **№** | **Чараның аталышы** | **план чоры** | |
| 1 | Төп җиһазларны ремонтлау | 2025 | |
| **6 нчы бүлек. Су белән тәэмин итүнең һәм ташландык суларны агызуның үзәкләштерелгән системалары объектларының ышанычлылыгы һәм энергетик нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең планлы күрсәткечләре** | | | |

| № | Күрсәткеч | Үлчәү берәмлеге | Күрсәткеч зурлыгы |
|---|---|---|---|
| | | | 2025 |
| 1ХВС – Эчә торган суга тариф – су белән тәэмин итү | | | |
| 1 | Эчә торган суның сыйфат күрсәткечләре | | |
| 1.1 | Дпс – Су белән тәэмин итү чыганакларыннан, сууткәргеч станцияләреннән яисә үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системасының башка объектларыннан бүлү сууткәргеч челтәренә билгеләнгән таләпләргә туры килми торган эчәр су пробаларының эчәр су сыйфатын производство тикшереп торуы нәтиҗәләре буенча алынган пробаларның гомуми күләмендә бирелә торган эчәр су пробалары өлеше | % | 0,00 |
| 1.2 | Дпрс – Бүлүче сууткәргеч челтәрендә эчәргә яраклы суның сыйфатын производство тикшереп торуы нәтиҗәләре буенча алынган пробаларның гомуми күләмендә билгеләнгән таләпләргә туры килми торган эчәргә яраклы су пробалары өлеше | % | 0,00 |
| 2 | Су белән тәэмин итүнең ышанычлылыгы һәм өзлексезлеге күрсәткечләре | | |
| 2.1 | Пн – Салкын су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системасы объектларындагы аварияләр, зарарланулар һәм башка технологик хокук бозулар нәтиҗәсендә салкын су белән тәэмин итү буенча салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы оешманың йөкләмәләрен үтәү урыннарында салкын су белән тәэмин итү шартнамәсендә, бердәй су белән тәэмин итү һәм су түгү шартнамәсендә яисә салкын су ташу шартнамәсендә билгеләнгән өзеклекләр саны салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы оешманың су белән тәэмин итүләре, елга сууткәргеч челтәренең озынлыгын исәпләп, бер елга | бер./км | - |
| 3 | Энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | | |
| 3.1 | Дпв – сууткәргеч челтәренә бирелгән суның гомуми күләмендә суны транспортировкалаганда үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системаларында су югалтулар өлеше | % | 2,70 |
| 3.2 | Урп – Эчә торган су әзерләүнең технологик процессында кулланыла торган электр энергиясе челтәргә җибәрелә торган су күләме берәмлегенә чагыштырма чыгымы | кВт*сәг/куб.м | 1,10 |
| 3.3 | Урп – Эчә торган суны транспортлауның технологик процессында кулланыла торган электр энергиясенең транспортлана торган эчә торган су күләме берәмлегенә чагыштырма чыгымы | кВт*сәг/куб.м | |

**7 нче бүлек. Үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системалары объектларының ышанычлылыгы, сыйфаты һәм энергетик нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең пландагы күрсәткечләренең һәм җитештерү программасын гамәлгә ашыру чыгымнарының аның гамәлдә булу чоры дәвамында үзгәреш динамикасын чагыштыру юлы белән гамәлгә ашырыла торган җитештерү программасының нәтиҗәлелеген исәпләү**

| № | Күрсәткеч | Үлчәү берәмлеге | Планлаштырыла торган чор күрсәткече зурлыгы |
|---|---|---|---|
| | | | 2025 |
| 1ХВС – Эчә торган суга тариф – су белән тәэмин итү | | | |
| | Үзгәреш динамикасын чагыштыру | % | Ышанычлылык, сыйфат һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең пландагы күрсәткечләре үзгәрешсез билгеләнә. |

**8 нче бүлек. Җайга салуның узган чорында җитештерү программасының үтәлеше турында хисап**

Җайга салуның узган чорында җитештерү программасының үтәлеше турындагы хисап оешманың 2023 елгы финанс-хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәләре турындагы хисабы составында бирелгән.

**9 нчы бүлек. Абонентларга хезмәт күрсәтү сыйфатын яхшыртуга юнәлдерелгән чаралар**

| № | Абонентларга хезмәт күрсәтү сыйфатын яхшыртуга юнәлдерелгән чаралар каралмаган. |
|---|---|